Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең Чуаш Чикилдеме торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында гражданнар җыены карары

13 .11. 2025 № 2

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуаш Чикилдеме торак пунктында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуаш Чикилдеме торак пункты территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Бакырчы авыл җирлегенең Чуаш Чикилдеме торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2000 ( ике мең ) сум күләмендә гражданнарга үзара салым кертергә.

2. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Чуаш Чикилдеме торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш, ком сатып алу, нигезне әзерләү, Ленин урамындагы 38 нче йорттан 42 нче йортка кадәр шартнамә буенча ташу, салу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Бакырчы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (https://tetushi.tatarstan.ru/) һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы " нда (https://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

Җитәкче И.М.Шәмсетдинов